РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ НОВОУСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**V ЧАКЫРЫЛЫШ XI УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р №17**

***Яңа Усы авылы*** ***“25” август 2026 нчы ел***

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 августындагы 45 номерлы «Яңа Усы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге советы **КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 августындагы 45 номерлы «Яңа Усы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының беренче утырышы тулы хокуклы составта уздырылган көннән туктатыла»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы** **Романова Г.С.**